КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 март г.Казань № 186

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм

илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче, 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче; 2017 ел, 26 май, 310 нчы; 2018 ел, 27 ноябрь, 1060 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен билгеләнә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пунктта «Дәүләт хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

2.3 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^{1}$ статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин